**Казанский (Приволжский) федеральный университет**
**Олимпиады школьников и студентов**

Место штампа

**Рабочий лист №1**

Дата "29" января 2025 г. (заполняется оргкомитетом)

**Шифр** ТЯ-17 (заполняется оргкомитетом)

## Оценка работы

(таблица заполняется по итогам проверки работы членами жюри олимпиады)

| № задания | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | Итого (итоговый балл, подпись председателя жюри) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Балл | 15 | 15 | 10 | 8 | 50 | | | | | | | | | | | 98б. |
| № задания | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 | 23 | 24 | 25 | 26 | 27 | 28 | 29 | 30 | |
| Балл | | | | | | | | | | | | | | | | |

Я-магистрант КФУ
(название олимпиады, заполняется участником)

Татарский язык и литература
(профиль олимпиады, заполняется участником)

⑤ Бөек Ватан сугышы — XX гасырның иң зур һәм иң канлы конфликтларының берсе. Бөек Ватан сугышы 1945 нче елның 9 нчы маенда Җиңү белән тәмамланды. Бу вакытта миллионлаган кеше, шул исәптән безнең бабайлар һәм әбиләребез, фронтта һәм тылда фидакарьлек күрсәтте.

Сугыш башлангач, илнең һәр кешесе фронтка ярдәм итү өчен үзенә тырышлык куйды. Хатын-кызлар, балалар һәм бикәләр тылда эшләделәр, азык-төлек җитештерделәр. Ирләр фронтка китеп, туганнары өчен яу кырында көрәште. Бөек Ватан сугышы барышында Совет солдатларының батырлыгы, тугрылыгы һәм патриотизмы искиткеч үрнәк булып тора.

Фатих Кәримнең әлеге шигырь юлында да безнең солдатларыбызның батырлыгы турындагы мәгънә салынган. Алар нинди генә авыр шартларда калсалар да, аның рухын югалтмыйча һаман җиңүгә таба атлаганнар. Үзләре турында уйламыйча, бары тик ил язмышын кайгыртканнар. Әгәр дә алар төшенкелеккә бирелеп утырган булсалар, көрәшергә дә авыр булыр иде. Үзләренең туган илләре, андагы якыннары хакында уйлаганга күрә, алар җиңеп тә чыга алганнар.

Минем әбиемнең әтисе дә Бөек Ватан сугышында катнашып, җиңү яулап кайткан. Ул сөйләгәнне тыңлап утырсаң, күзгә яшьләр килә. Шуның өчен дә мин үземнең бабам белән бик тә горурланам. 50

Бөек Ватан сугышы безнең тарихыбызда мәңгелек урын алырга тиеш. Без бу сугышта катнашкан барлык кешеләрне онытмаска, аларның батырлыгын хөрмәт итәргә тиешбез. Җиңү — ул бары тик хәрби уңыш кына түгел, ә безнең халыкның берләшлеге, көчле рухы һәм туган илгә мәхәббәте символы. Бүгенге көндә без бу истәлекне саклап калырга, киләчәк буыннарга җиткерергә бурычлыбыз.



Сдано 1 листов

① Семасиология – сүзләрнең мәгънәсен, мәгънәләр үсешен, үзгәрешен өйрәнә.

Ономасиология – лексикологиянең әйбер, күренешләргә атама бирү закончалыкларын өйрәнү.

Фразеология – фразеологик берәмлекләрне, ягъни фразеологизмнарны, аларның структурасын, мәгънәсен һәм кулланышын өйрәнә.

15 Әлеге өлкәдә Галиуллина Г.Р. зур көч куйган.
Шулай ук Баширов, Әхтәмов, Гобәева, Мәхмутова-лар зур өлеш керткән.

② а) Мәһабәт төз наратларның очлары ягъни нурга манчылып, рәхәт бер тынычлыкка бирелгәндәй шып та итмичә тик кенә торалар.

ә) уянып – хәл фигыль, барлыкта, затланышсыз, төп юнәлештә, җөмләдә хәл булып килгән.
Соенә-соенә – хәл ф, барлыкта, затланышсыз, төп юнәлештә, җөмләдә хәл.

Уйнаган – фигыль, затланышсыз, сыйфат ф, барлыкта, заман белән
15 төрләнә, үткән заманда, ~~җөмләдә хәбәр булып килә~~ җөмләдә аергыч булып килә.

Күңелдерәләр – фигыль, хикәя фигыль, затланышлы, барлыкта, III зат күплек санда, заман белән төрләнә, хәзерге заманда, төп юнәлештә, җөмләдә хәбәр булып килә.

④ Беренче пьесалар арасында – Г. Ильясиның „Бичара кыз", Ф. Хәлидинең „Рәддә бичара кыз" мелодрамалары, билгесез авторның рус теленнән иркен тәрҗемәдә „Комедия истанбулда" комедиясе, М. Ю.-Казанлының романтик мәзәраны „Үсмерләргә кыз" драмасы, Г. Камалның „Өч бәдбәхет", „Бәхетсез егет" драмалары, Г. Исхакыйның „Өч хатын белән тормыш" драмасы. Бу пьесаларда мәгърифәтчелек, хисс, аерылу, хатын-кыз ирек, мәсьәләләре, актуальлек, яшәештәге искелек билгеләре, ~~надан~~ шулай ук наданлык күренешләре тәнкыйтьләнә.
8 Алар реаль тормышны чагылдыра, әмма аларның поэтикалары камиллектән әле ерак тора, бу хәл сюжет сызыгын һәм образлар системасын төзүдә күренә. 67

③ Лиро-эпика төре – лирик һәм эпик элементларны берләштерә. Лиро-эпик әсәрләр күп очракта поэтик формада язылган.
Төп үзенчәлекләре: лирик элементлар, эпик элементлар (тарихи яки мифологик сюжетлар), ~~эк~~ поэтик форма (шигъри формада язылган, ритм һәм рифма куллану)
Тематика: лиро-эпик әсәрләрдә мәхәббәт, туган илгә мәхәббәт, фидакарьлек, табигать өчен бәйле кисәләр кебек темалар киң таралган.
10 Мисаллар: „Сак-Сок" бәете, Г. Тукайның „Шүрәле" поэмасы.

Бу әсәрләрдә автор геройларның эчке дөньясын һәм социаль контекстны күрсәтә.